ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.10.2023 г. Казань № 320-4/соц-2023

Коммерциясез оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүгә тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 һәм 2024 елларда «Коммерциясез оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» сынау проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 елның 18 июлендәге 860 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2023 елның 6 октябрендәге 42-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, коммерциясез оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүгә тариф билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән алып 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
06.10.2023 № 320-4/соц-2023
карарына кушымта

Коммерциясез оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүгә тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | Коммерциясез оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга булышлык күрсәтеп яшәтү буенча социаль хезмәт күрсәтү | сум/сәгать | 52,56 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге